ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.04.2020 № 191

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 15.05.2012 ел, № 528 карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 27 декабрендәге 558-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе Торак кодексына күпфатирлы йорттагы биналарны үзгәртеп коруны һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә үзгәрешләр кертү турында" Федераль законга, 29.05.2019 елдагы 116-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районында торак булмаган биналарны торакка, һәм торак биналарны торак булмаган биналарга күчерү турындагы документларны карау һәм рәсмиләштерү тәртибен раслау турында" 2007 ел, 22 нче октябрь, 1003 номерлы карары белән расланган Торак булмаган биналарны торакка, һәм торак биналарны торак булмаган биналарга күчерү турындагы документларны карау һәм рәсмиләштерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.9 пунктның 4 пунктчасында "торак урыны" сүзләрен "күпфатирлы йортта бина" сүзләренә алмаштырырга .

Административ регламентның 2.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пунктлар белән тулыландырырга:

"7) күпфатирлы йортта биналар милекчеләренең гомуми җыелышының торак бинаны торак булмаган бинага күчерү ризалыгы турында карарны үз эченә алган беркетмәсе;

8) күчерелә торган бинага якын булган барлык биналарның һәр милекчесенең торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы.".

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов